# КАРАР

**30 май, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 30 маенда түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

2 нче пунктның икенче абзацын «юлга вак таш җәю, Иске Кенә-Юмья авылының Мәскәү урамында баш-башларны ныгытып, су үткәрү торбасын озынайту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру» сүзләре тулыландырырга

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 259 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 132 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 132 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы» дигән мәсьәлә буенча карарны

2 нче пунктның икенче абзацын «юлга вак таш җәю, Иске Кенә-Юмья авылының Мәскәү урамында баш-башларны ныгытып, су үткәрү торбасын озынайту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру» сүзләре тулыландырырга

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев